| ГЛАВА<br>САРСАК-ОМГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>САРСАК-УМГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.10.2024 Сарсак-Умга авылы № 3

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Сарсак-Умга авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең Татар Таңсары авылында гражданнар җыенын билгеләү турынд

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлеге Уставының 14 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлеге башлыгы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Сарсак-Умга авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Татар Таңсары торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2024 елның 8 ноябрь көнне 10 сәгать 00 минутта билгеләргә.

2. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы “Сарсак-Умга авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Татар Таңсары торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, студентлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче затлардан һәм ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгән, ирекле рәвештә киткәннәрдән) һәм аларның гаилә әгъзаларын (аларның ата-аналарын, хатыннары, балигъ булмаган балаларын) түләүдән азат итеп һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне үтәү буенча алынган мәсьәләләрне хәл итүгә юллап, түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдереп, гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга: 2025 елда үзара салым акчасын 500 сум күләмендә кертү һәм куллану белән килешәсезме?”:

- Татар Таңсары торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Нагорная

урамындагы чокырларны ремонтлау өчен вак таш сатып алу һәм салу һәм автомобиль юлларын карап тотуның башка чыгымнары);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (торак пункт урамнары юлларын кардан чистарту һәм территорияне төзекләндерү буенча башка чыгымнар)

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. рažданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Татар Таңсары авылы, Тау асты ур., 3 нче йорт янындагы мәйданчык.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлеге Башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлегенең мәгълүмат стендында игълан итәргә, «Интерне» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Т.С. Николаева